МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.05.2019 Казан ш. № под-845/19

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршында иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 01 июнендәге 6536/15 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршында иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршында иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 01 июнендәге 6536/15 номерлы боерыгы (2015 елның 14 сентябрендәге под-9277/15 номерлы, 2016 елның 06 июнендәге под-1115/16 номерлы, 2018 елның 17 гыйнварындагы под-69/18 номерлы, 2018 елның 20 августындагы под-1226/18 номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре) белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршында иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупциячел торышка сабырсызлык формалаштыру.»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый советта каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм

бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар һәм белгечләр чакырылырга мөмкин.».

2. Юридик бүлеккә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.И.Поминовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов